Республика Татарстан
Совет Старомензелябашского
сельского поселения Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
Советы

РЕШЕНИЕ

КАРАР
№ 5

2024 ел 30 март

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлегендә
муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 пунктына, Сарман муниципаль районының «Иске Минзәләбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә, Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советының 2022 елның 14 февралендәге 4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1) 5.5 пунктны 13 пункт белән тулыландырырга) түбәндәге эчтәлектәге:

«13) яллаучының (эш бирүченең) вәкиленә әлеге Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкетадагы мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итәргә, яллаучының (эш бирүченең) вәкиле карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш (алга таба - анкетада булган мәгълүматлар).».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
Советы рәисе

А.Н.Габдрахманов